**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Янил авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 10 ноябре** **№ 6**

**«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 27 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 27 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахитово авылы, Клуб урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 27 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитово авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вахит авылында юлларны кышын һәм җәен карап тоту (чистарту, кардан арындыру), килешү буенча түләү;
- Вахит авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү;
- Вахит авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү;
- Вахит авылында җәяүлеләр территорияләрен, тротуарларны ясау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру һәм килешү буенча түләү;

- чишмәне төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү (материаллар сатып алу, проект-смета документларын төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү);

- парк территориясен төзекләндерү (җәен һәм кышын тротуарларны карап тоту, газон үләнен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, артобъектлар, МАФ сатып алу, проект-смета документациясен төзү, килешү буенча түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Янил авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893